| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 30 декабрь г.Казань № 1226

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1271 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының « 2020 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1271 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 21 декабрь, 1167 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

икенче абзацта «23 783 574,87» саннарын «26 659 814,30345» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «260 766,4 мең сум күләмендә субсидияләр рәвешендә федераль бюджеттан кергән һәм 267 024,549 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары» сүзләрен «260 672,497 мең сум күләмендә субсидияләр рәвешендә федераль бюджеттан кергән һәм 266 928,394 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «14 096,63639» саннарын «12 429,46777» саннарына, «1 789,75702» саннарын «1 746,26965» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«2013 - 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциячел булмаган берләшмәләренә керү юлларын ремонтлауга юнәлтелгән программаны 300 000,0 мең сум күләмендә;

Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсеше өчен аеруча мөһим булган 340 000,0 мең сум күләмендә федераль бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган проектларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән программаны;

«Экономик үсеш һәм инновацион икътисад» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Туризм» ярдәмче программасы кысаларында туристик кластерлар төзү буенча инвестиция проектлары составына керүче, федераль бюджеттан 109 475,1 мең сум күләмендә субсидияләр рәвешендә кергән акчалар һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан 79 275,1 мең сум күләмендә акчалар исәбеннән финансланучы тәэмин итүче инфраструктура объектларын төзү (реконструкцияләү) буенча чараларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән программа;

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 47 898,42176 мең сум күләмендә финансланучы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» монопрофильле муниципаль берәмлегендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзүгә һәм (яисә) реконструкцияләүгә юнәлдерелгән программа;

«Юл эшләре программаларын финанслау дирекциясе» дәүләт бюджет учреждениесенә субсидия исәбеннән юл эшләрен башкару чараларын гамәлгә ашыруга юнәлтелгән программаны 7 583 294,272 мең сум күләмендә;

2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы бюджеты акчаларының калган өлеше исәбеннән финанслана торган юл эшләре күләмнәре, Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә каралган, шушы дәүләт контрактлары шартлары нигезендә 2019 елда 848 365,29494 мең сум күләмендә түләнергә тиешле дәүләт контрактлары өчен түләүгә каралган 2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы бюджетының калган акчалары исәбеннән финанслана.»;

2 пунктта «28 883 052,21241» саннарын «36 350 040,01893» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2020 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасын, «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» ярдәмче программасының гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәреннән авыл торак пунктларының якындагы иҗтимагый әһәмияткә ия объектларына, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү объектларына алып бара торган каты өслекле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм реконструкцияләү чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән программаны, Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре монопрофильле муниципаль берәмлегендә инвестицион проектларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә юнәлдерелгән программаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгәннәр):

әлеге карарга «2013-2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциячел булмаган берләшмәләренә керү

юлларын ремонтлауга юнәлдерелгән программаны, Россия Федерациясе социаль-икътисадый үсеше өчен аеруча мөһим булган проектларны гамәлгә ашыруны күздә тоткан чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән программаны, «Икътисадый үсеш һәм инновацияле икътисад» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Туризм» ярдәмче программасы кысаларында туристик кластерлар төзү буенча инвестиция проектлары составына керүче озак вакыт аклану срогы белән тәэмин итүче инфраструктура объектларын төзү (реконструкцияләү) чараларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән программаны, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» монопрофильле муниципаль берәмлегендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә юнәлдерелгән программаны, «Юл эшләре программаларын финанслау дирекциясе» дәүләт бюджет учреждениесенә субсидияләр исәбеннән юл эшләрен башкару чараларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән, 2020 елда Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган юл эшләре күләме, Татарстан Республикасы исеменнән 2019 елда әлеге дәүләт контрактлары шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән дәүләт контрактлары шартлары нигезендә түләүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә карата Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән 2020 елның 1 гыйнварына каралган программаны өстәргә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин